# ТЕЛ – РУХИ БАЙЛЫГЫБЫЗ.

***2000 НЧЕ ЕЛДА БЕРЛӘШКӘН МИЛЛӘТЛӘР ОЕШМАСЫ, ЮНЕСКО ИНИЦИАТИВАСЫН ХУПЛАП, КҮПТЕЛЛЕЛЕКНЕ ЯКЛАУ ЙӨЗЕННӘН 21 НЧЕ ФЕВРАЛЬНЕ “ХАЛЫКАРА ТУГАН ТЕЛ КӨНЕ” ИТЕП ҮТКӘРҮ ТУРЫНДА КАРАР КАБУЛ ИТТЕ.***

БҮГЕН ТЕЛЛӘР БЕЛҮ ЯХШЫ ҺӨНӘРДЕР.
КАТЫШТЫРМА ВӘ ЛӘКИН ТЕЛГӘ ТЕЛНЕ.
ТЕЛ УЙНАТМАК НАДАНЛЫКТАН ӘСӘРДЕР

ДӘРДЕМӘНД

ТУГАН ҖИРЕҢ – ИДЕЛ БУЕ
ҺӘР ТЕЛНЕҢ БАР ТУГАН ИЛЕ
ТУГАН ҖИРЕҢ КЕБЕК НАЗЛЫ,
ҖЫРДАЙ МОҢЛЫ ТАТАР ТЕЛЕ.

Н.НӘҖМИ

ДАНЛЫ ҖИРНЕҢ, ГАЗИЗ ҖИРНЕҢ
УЛЫ БУЛЫП ТУГАН КӨНЕМ,
РӘХМӘТ СИҢА!
ҖЫР БУЛЫРЛЫК СҮЗЛӘР БИРГӘН
МАТУР ТЕЛЕМ, ТУГАН ТЕЛЕМ,
РӘХМӘТ СИҢА!

Г.НӘБИУЛЛИН

МИНЕМ ТЕЛЕМ,-
МЕҢӘРЛӘГӘН ИШЛӘРЕ КҮК,
МОҢЛЫ ТЕЛ УЛ,
ҮЗЕНӘ ҖАЙ, ҮЗЕНӘ ЯТЫШ
АНЫҢ КӨЕ:
“САК-СОК”ЛАРЫ, “РАМАЙ”ЛАРЫ,
“САРМАН”НАРЫ, “ГӨЛҖАМАЛЫ”,
“КАРУРМАН”Ы, “ӘЛЛҮКИ”Е.

Р.ФӘЙЗУЛЛИН

ТЕЛ ДИГӘН ДӘРЬЯ БАР,
ДӘРЬЯ ТӨБЕНДӘ МӘРҖӘН БАР,
БЕЛГӘННӘР ЧУМЫП АЛЫР,
БЕЛМӘГӘННӘР КОРЫ КАЛЫР.

ТЕЛ – БЕЛЕМНЕҢ АЧКЫЧЫ,

АКЫЛНЫҢ БАСКЫЧЫ.

МӘРХӘМӘТЛЕ БУЛ СИН
ТУГАН ТЕЛГӘ, ИХТИРАМЛЫ
БУЛ СИН, ТУГАН СҮЗЛӘРГӘ.
СҮЗНЕ КИРӘК МӘҢГЕ
ЯРАТЫРГА,
СҮЗНЕ КИРӘК МӘҢГЕ
ЭЗЛӘРГӘ!

ТУГАН ТЕЛЕН КАДЕРЛӘГӘН ХАЛЫК КАДЕРЛЕ БУЛЫР.

ТАТАР МОҢЫ!
ЕРАК ТАРИХЛАРДАН
АЛЫП КИЛӘ ХАЛЫК ХӘТЕРЕН.
ОЯЛЧАН УЛ, ИНСАФЛЫ ҺӘМ ЯГЫМЛЫ УЛ –
ҮЗЕ САЛМАК, ҮЗЕ ӘКРЕН.
МИН ХӘЗЕР ДӘ ҮЗӘК ӨЗЕЛГӘНДӘ,
ҖЫРЛАР КАНАТЫНДА ТИРБӘЛӘМ.
КАЙГЫ КИЛЕП, БАШЫМ ИЕЛСӘ ДӘ,
СӨЕНСӘМ ДӘ ҖЫРЛАП ҖИБӘРӘМ.

ТЕЛ — ХАЛЫКНЫҢ ГОРУРЛЫГЫ,
ЯШӘВЕ ҺӘМ БАРЛЫГЫ.
ЧИКСЕЗ КЫЙММӘТЛЕ ХӘЗИНӘ,
АНЫҢ РУХИ БАЙЛЫГЫ.
ТЕЛ КАЙГЫНЫ УРТАКЛАША,
КУАНДЫРА, ХУШ ИТӘ.
ЙӨРӘКЛӘРНЕ КАВЫШТЫРА,
КЕШЕЛӘРНЕ ДУС ИТӘ.

ӘТКӘҢ-ӘНКӘҢ ТЕЛЕН БЕЛСӘҢ,
АДАШМАССЫҢ КАЙДА ДА...
ТУГАН ТЕЛЕМДӘ ЭНДӘШӘМ
КОЯШКА ДА,АЙГА ДА.
ТУГАН ТЕЛЕМДӘ АҢЛАШАМ
ҮТКӘН, БУГЕНЕМ БЕЛӘН. ..
ӘЛИФБАМНЫ ДОГА ИТЕП
УКЫЙМЫН КҮҢЕЛЕМНӘН.
ИГЕЛЕКЛЕ БУЛЫП ҮСИМ
ГАЗИЗ ТУГАН ТЕЛЕМӘ.
ТУГАН ТЕЛ БЕР ГЕНӘ БУЛА-
ӘНКӘЙ КЕБЕК БЕР ГЕНӘ.

**МИЛЛИ ТЕЛ — МИЛЛӘТ ЯШӘЕШЕНЕҢ НИГЕЗЕ. КЕШЕ ҺАВА СУЛАМЫЙЧА ЯШИ АЛМАГАН КЕБЕК, МИЛЛӘТ ТӘ ТЕЛСЕЗ ЯШИ АЛМЫЙ. МИЛЛӘТ — ТЕЛЕ БУЛГАН ХАЛЫК УЛ. Ә МИЛЛИ ТЕЛНЕҢ НИГЕЗЕ — АНА ТЕЛЕ.**

ҮЗ АНА ТЕЛЕМ — МИНЕМ ӨЧЕН МАТУР, ИҢ ТӘМЛЕ ТЕЛ,
ҮЗ ТЕЛЕМ — ҮЗ ӘЙБЕРЕМ БУЛГАН ӨЧЕН ЯРАТА КҮҢЕЛ.
ШУЛ АНА ТЕЛЕ БЕЛӘН МИН МАКСАТЫМНЫ АҢЛАТАМ,
ШУЛ АНА ТЕЛЕ БЕЛӘН «БАЛА» ДИЛӘР АТА-АНАМ.
ШУЛ ТЕЛ АРКЫЛЫ ГЫЙЛЕМ, УКУ-ЯЗУНЫ ӨЙРӘНӘМ,
ШУЛ ТЕЛ АРКЫЛЫ УКЫП, БУЛЫРМЫН ЧЫН АДӘМ.
ӘЛЕ ДӘ ШУЛ ТЕЛ БЕЛӘН УКЫЙМ, ЯЗАМ ҺӘМ СӨЙЛӘШӘМ.
ШУЛ ТАТАР ТЕЛЕ БЕЛӘН КӨЙЛИМ БЕРӘР КӨЙ КӨЙЛӘСӘМ.

ТАТАР ТЕЛЕ – ДУСЛЫК ТЕЛЕ:
ТӨРКИ ХАЛКЫН ЯКЛАГАН.
ТАТАР ТЕЛЕ – ХАННАР ТЕЛЕ,-
ЗУР ТЕЛЛӘРДӘН КАЛМАГАН.

Ассалар да, киссәләр дә,
Көчләп тәре элсәләр дә
Дөньяда – татар телем,
Кол Гали, Тукай телем.